ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Физик культура һәм спорт турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2022 елның 16 мартында
кабул ителде

**1 статья**

«Физик культура һәм спорт турында» 2008 елның 8 октябрендәге 99-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2008, № 10 (I өлеш); 2010, № 6 (I өлеш); 2011, № 5; 2012, № 7 (I өлеш), № 12 (II өлеш); 2013, № 6 (II өлеш); 2014, № 1–2, № 7, № 12 (II өлеш); 2015, № 3, № 7 (I өлеш), № 10 (I өлеш), № 11 (I өлеш); 2016, № 3, № 10; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 27 (I өлеш); 2018, № 29 (I өлеш), № 54 (I өлеш); 2020, № 87 (I өлеш); 2021, № 29 (I өлеш), № 49 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3 статьяның 11 пунктында «, мәктәп спорты» сүзләрен «(мәктәп спортын да кертеп)» сүзләренә алмаштырырга;

2) 5 статьяның 6 пунктында «спорт судьялары,» сүзләреннән соң «тренер-укытучылар (алга таба шулай ук – тренерлар)» сүзләрен өстәргә;

3) 6 статьяда:
а) 1 өлештә:
$1^{1}$ пунктта «, мәктәп спортын» сүзләрен «(мәктәп спортын да кертеп)» сүзләренә алмаштырырга;
$4^{1}$ пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«$4^{1}$) балалар-яшүсмерләр спортын үстерү;»;
$9^{1}$ һәм $9^{3}$ пунктларны үз көчләрен югалткан дип танырга;
б) 2 өлешнең 2 пунктында «тренировка» сүзен «укыту-тренировка» сүзенә алмаштырырга;

4) 9 статьяның 2 өлешендә «тренировка» сүзен «укыту-тренировка» сүзенә алмаштырырга;

5) 11 статьяда:

а) 1 өлештә «тренировка» сүзен «укыту-тренировка» сүзенә алмаштырырга;

б) $4^1$ өлешнең 1 пунктында «тренировка» сүзен «укыту-тренировка» сүзенә алмаштырырга;

6) 14 статьяның 4 өлешендә «спорт әзерлеген гамәлгә ашыручы оешмалар» сүзләрен «спорт әзерлеге буенча өстәмә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы оешмалар» сүзләренә алмаштырырга;

7) 18 статьяда:

а) 2 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Спорт әзерлеге узучы затның спорт әзерлеге буенча өстәмә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы оешмага каравы мондый оешманың әлеге затны Россия Федерациясе бюджет системасы тиешле бюджетының бюджет ассигнованиеләре исәбеннән дәүләт заданиесе (муниципаль задание) яисә түләүле белем бирү хезмәтләре күрсәтү турындагы шартнамә нигезендә спорт әзерлеге буенча өстәмә белем бирү программасы буенча укырга кабул итү турындагы боеру акты нигезендә билгеләнә.»;

б) 3 өлешне үз көчен югалткан дип танырга.

8) 19 статьяның 2 өлешендә:

а) 2 пунктта «физкультура-спорт ягыннан әзерләүнең» сүзләрен «физик яктан үстерү һәм физик әзерләү буенча» сүзләренә алмаштырырга, «чараларын» сүзен «чаралар» сүзенә алмаштырырга;

б) 3 пунктта «физик культура күнекмәләре» сүзләрен «хәрәкәтләнү күнекмәләре, физик культура турында белемнәр» сүзләренә алмаштырырга;

в) 4 пунктта «дәресләр вакытында» сүзләреннән соң «һәм дәресләрдән тыш вакытта» сүзләрен өстәргә;

9) 22 статьяның 7 өлешендә «балалар-яшүсмерләрнең спорт-адаптив мәктәпләрен» сүзләрен «спорт мәктәпләрен, шул исәптән адаптив спорт буенча спорт мәктәпләрен» сүзләренә алмаштырырга;

10) 23 статьяның 2 өлешендә «эшләүне оештыру» сүзләрен «эшләү» сүзенә алмаштырырга;

11) 24 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«24 статья. **Спорт әзерлеген оештыру**

Спорт әзерлеген оештыру Федераль закон нигезендә гамәлгә ашырыла.»;

12) 25 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«25 статья. **Федераль спорт әзерлеге стандартларының үтәлешенә җәмәгать контроле**

Бөтенроссия спорт федерацияләре һәм аккредитацияләнгән республика спорт федерацияләре, аларның вәкилләре спорт әзерлеге буенча өстәмә белем бирү программаларын гамәлгә ашыра торган оешмалар тарафыннан тиешле спорт төрләре буенча федераль спорт әзерлеге стандартларының үтәлешенә җәмәгать контролен физик культура һәм спорт өлкәсендә федераль башкарма хакимият органы билгеләгән тәртиптә гамәлгә ашырырга хокуклы.»;

13) 26 статьяда:

а) исемдә «, республика спорт әзерлеге үзәкләре» сүзләрен өстәргә;

б) түбәндәге эчтәлекле 5 өлеш өстәргә:

«5. Республика спорт әзерлеге үзәкләре физик культура һәм спорт өлкәсендә Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең махсус вәкаләтле органы тәкъдиме белән Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары нигезендә оештырыла.»;

14) 29 статьяның 2 өлешендә «спорт әзерлеген гамәлгә ашыра торган» сүзләрен «спорт әзерлеге буенча өстәмә белем бирү программаларын гамәлгә ашыра торган» сүзләренә алмаштырырга.

**2 статья**

Әлеге Закон 2023 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ • АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2022 ел, 24 март
№ 17-ТРЗ